**Р Е С П У Б Л И К А**
**Т А Т А Р С Т А Н**
**Г Л А В А**
**Балтачевского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**м у н и ц и п а л ь н о г о р а й о н а**

**ул. Школьная, 1, с. Балтачево,**
**Камско-Устьинский район, 422829**
**тел./факс: (84377) 3-66-40**
**ОГРН 1061672018044**
**ИНН/КПП 1622004637/162201001**

**Т А Т А Р С Т А Н**
**Р Е С П У Б Л И К А С Ы**
***Кама Тамагы***
**м у н и ц и п а л ь р а й о н ы**
**Балтач авыл жирлеге**
**Б А Ш Л Ы Г Ы**

**Мэктэп урамы, 1, Балтач авылы,**
**Кама Тамагы районы, 422820,**
**тел./факс: (84377) 3-66-40**
**ОГРН 1061672018044**
**ИНН/КПП 1622004637/162201001**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 15 октябре** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халыкжыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2020 елның 31 октябрендә 11 сәгать 00 минутка халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән , I төркем инвалидларыннан тыш , 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү, һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Балтач авылында җирлек эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау;

- Балтачево авылындагы коены ремонтлау;

Балтач авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау (скважиналарның санитар-саклау зоналарын коймалау, чыгым материаллары сатып алу);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль район, Балтач ав., Мәктәп ур., 1,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мәктәп урамы, 2 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәТатарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң 2 (ике) көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Балтач
авыл җирлеге башлыгы Д.И. Мөхәмәдуллин